Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___16.03.2026_____ Менделеевск ш. № ____172______

«2025-2027 елларга Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында физик
культураны һәм спортны үстерү» район
муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» район муниципаль программасының программа чаралары исемлегенә төзәтмәләр кертүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының “2025-2025 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү район муниципаль программасын (алга таба-программа) раслау турында” 2025 елның 3 февралендәге 71 нче номерлы карары белән расланган «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» район муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның “Программа чаралары исемлеге " VI бүлегенең 3 пунктындагы 3.5 пунктчасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.5 | Спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыруга һәм Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары командаларын | «Айсберг» СМ МБУ | 2025-2026 | ТР бюджеты | 627,6 | 539,2 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ың хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында һәм хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында (А төркемчәсе) катнашуына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү | | | | | | |

1.2. Программаның “Программа чаралары исемлеге" VI бүлегенең 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5.2 пунктча өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.2 | Спорт мәктәпләренең спорт җиһазлары, инвентарьлары һәм экипировкалары сатып алу | Спорт мәктәпләре | 2025-2027 | ТР чаралары | 469,69 | 467,31 | |

1.3. Программаның “Программа чаралары исемлеге" VI бүлегенең 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5.4 пунктчалар өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.4 | Физик культураны, массакүләм спортны үстерү, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру өчен шартлар тәэмин итүгә бәйле чараларны гамәлгә ашыру | Спорт мәктәпләре | 2025 - 2026 | ТР бюджеты<br><br>җирле бюджет | 106,7752<br><br>5,33876 | 427,13<br><br>21,3565 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны йөртү буенча аутсорсинг буенча хезмәтләр алуга бәйле рәвештә физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләрнең муниципаль биремнәрне үтәвен финанс белән тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә | | | | | | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ю.М. Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Искаков